**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3830

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лэйсэн» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лэйсэн» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лэйсэн» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрендәге 5532 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «19» 11. 3830 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ләйсән» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Иҗат остаханәсе» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Тылсымлы пәрдә» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Познавайка» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 гыйнвареннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Иҗат остаханәсе» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Тылсымлы пәрдә» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Познавайка» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ләйсән» балалар бакчасы мөдире _______________ Д.Х. Кашапова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ләйсән» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Иҗат остаханәсе»** - программа укучыларда рәсем, сәнгать-конструкторлык сәләтен, стандарт булмаган фикерләүне, иҗади индивидуальлекне үстерүне күздә тота.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 45 кв.м, балалар саны - 10.

2. **«Тылсымлы пәрдә»** - программа актерлык осталыгы, вокал, хореография һәм импровизация элементларын берләштерә.

Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 70 кв.м, балалар саны - 10.

3. **«Познавайка»** - прооgrамма сөйләм үсешенә, вак моторикага, сенсор үсешенә, логик фикерләүгә һәм балаларның танып белү активлыгына юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м, балалар саны - 10.

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль
бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе –
«Ләйсән» балалар бакчасы мөдире ________________ Д.Х. Кашапова